Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 21 от 10.10.2025ел..

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитетының «Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләренә премияләр түләү тәртибе турында Нигезләмәне, еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм түләү һәм бер тапкыр бирелә торган түләү тәртибен, матди ярдәм түләү тәртибен раслау хакында» 2018 елның 04 маендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитетының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләренә премияләр түләү тәртибе турындагы нигезләмәне, еллык түләүле отпускны биргәндә матди ярдәм түләү һәм бер мәртәбә түләү тәртибен, матди ярдәм түләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 04 маендәге 6 номерлы карарына (2021 елның 03 июнендәге 18 номерлы, 2022 елның 02 февралендәге 4 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Матди ярдәм түләү тәртибе» 3 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: А.В. Алиев

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитетының 2025 елның «10» октябрендәге 21 номерлы карарына кушымта.

## Матди ярдәм түләү тәртибе

1. Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү фонды акчалары чикләрендә хезмәткәрнең шәхси гаризасы буенча матди ярдәм түләү каралган:

- табигый бәла-каза белән (янгын, су басу, башка табигый бәла-каза һәм башка шундый хәлләр нәтиҗәсендә хезмәткәрнең мөлкәте юк ителү яисә зыян күрү);
- хезмәткәрнең авыруы (хирургик операция үткәрүгә һәм озак вакыт дәвалануга бәйле);
- якын туганнары (әтисе, әнисе, ире, хатыны, балалары) үлсә.
- 50 һәм 55 яшькә җиткән хатын-кызларга, 50 һәм 60 яшькә җиткән ир-атларга юбилей даталары уңаеннан.

2. Авыл җирлеге башлыгына матди ярдәм күләме айлык түләүнең 50 процентыннан артмаска тиеш.

Муниципаль хезмәткәрләргә һәм хезмәткәрләргә матди ярдәм күләме вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаска тиеш.

Хезмәт хакы Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәткәрләргә матди ярдәм күләме тариф ставкасының (окладның) 50 процентыннан артмаска тиеш.

3.Хезмәткәргә матди ярдәм, коллектив җыелышы беркетмәсе нигезендә, Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә түләнә.

4. Хезмәткәргә матди ярдәм түләү тәртибенең 1 пунктында күрсәтелгән очрак килеп чыккан бер финанс елы дәвамында түләнә.